Курчаклар турында сойлэгэндэ, без бары тик балачакка гына морэжэгать итэр идек, эмма олкэннэр очен дэ курчак лар барлыгын белэбез. Узган гасырнын 20-30 елларында ук Европада курчак-ларга мода барлыкка килv дэ юкка гына тvгел.

Курчак - ул магик чик. Ана кvзлэр ясат-кач, ул vз тормышы белэн яши башлый. Кvзлэре - кvнел козгесе, дип юкка гына эйтмилэр.       Ә аны булдырганда яхшы кэ-ефтэ булу моһим. Мондый «коч» остасы Ригина Раиль кызы Алукаева. Анын кур-чакларын кулдан тошерэсе килми алар-да жылылык, унайлылык һэм тынычлык бар.

Кыскача язма героебыз белэн таны-шып алыйк. Саранск кызы Ригина Ра-иль кызы Лэмберэ районы Аксён авы-лы егетенэ киявгэ чыга. Авыл клубында эшли башлый. Курчаклар ясау турын-да уй ничек килде сон ана; бу гаилэ традициялэренэ дэ бэйле тvгел. Барысы да бик гади: курчак тегvне кvрэ, техника-сы белэн таныша һэм бу эш ошап китэ. Хэзер Аксён авылы мэдэният йортында бу юнэлештэ кызыксыну буенча клуб эшли. Житэкчесе – Ригина Раилевна. Анда тегv һэм чигv - кvнел һэм йорэк очен ин сойкемле һэм файдалы шогыль белэн авыл хатын-кызлары шогыльлэнэ. Алукаева Ригина Раиль кызы белэн янэшэдэ гомер итvче пенсионер укы-тучы Луиза Абдрахман кызы Равилова, физика укытучысы Наилэ Муся кызы Юсупова кул эшлэре артында бергэлэп ял итэ. Алар чигэлэр, тозлы камырдан эшлэнмэлэр ясыйлар. Ботенроссия Сабантуе кvргэзмэсендэ катнашуны кvздэ тотып, чигелгэн эһэмиятле эшлэр арасында Луиза Абдрахман кызынын «Мэчет», «Атлар» чигvе, Наилэ Муся кызынын «Кол Шэриф» дигэн чигvлэрен кvрэчэкбез.

Курчак ясау техникасы кызыклы, шуна игътибар итик. Курчаклар «ирлэр» һэм «хатын-кызлар»га бvленгэнлектэн, алар очен материаллар да торле. Мэсэлэн, шундый материаллардан да ясала: по-ролон, кvн, тыгыз тукыма...

Курчаклар ясау осталыгы ерак борын-гыга барып тоташа. Алар магик ритуал-ларда һәм тормышта ин әһәмиятле ва-кыйгаларда, шулай ук бәйрәмнәр очен кулланылган. Әйтик, ойләнешvчеләр очен «аерылгысызлар» - куллары берсе-бесенә тоташкан ике курчак бар. Ри-гина Раиль кызы жептән дә курчаклар ясау техникасын vзләштергән. Элек мондый эшләнмәләрне курчак-моталка дип атаганнар. Аларны хәтта кечкенә балалар да ясый белгән; бу унай магик vзенчәлекләрдән тыш, вак моторика vсешенә дә ярдәм итә. Алар юлчыны са-клап, йорт почмакларынын саклау деко-ры булып та хезмәт иткәннәр.

Р.Р.Алукаева коллекциясендә торле милли киемнәрдәге курчаклар да бар: рус, татар, мордва. Кvзенне чу-алта тосләр жыелмасы! Бу, әлбәттә, чvпрәктән ясалган курчаклар, доньяда ин кин таралганнары. Мондыйлар элек хужаларына гомере буе хезмәт иткән. Курчак нәсел очен кочле талисман дип санала.

Алда - Ботенроссия авыл Сабантуе. Бел-гәнебезчә, ул Аксёново авылы мәй-данчыгында узачак. Биредәге осталар экспозицияне ачачак, анда аларнын ижат жимешләрен тәкъдим итәчәкләр. Ригина Раиль кызы Алукаеванын кайгыртучан-лыгы һәм осталыгы белән рухландырган искиткеч эшләре дә булачак. Бу курчак-лар Сабантуйнын сакчылары – оберегы.

Чын-чынлап изге һәм милли курчак-ларны карап сокланырга момкин була-чак.